| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУСЛЮМОВСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>**СОВЕТ НИЖНЕТАБЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>**ТҮБӘН ТАБЫН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |
|---|---|---|

*Юрид.адрес: 423977, РТ, Муслюмовский район, с. Нижний Табын, ул. Молодёжная, 10*
*Факт.адрес: 423977, РТ, Муслюмовский район, с. Верхний Табын, ул. Тукая, 21а*
Тел./факс: 8-85556-32874/Элект. адрес: Ntab.Mus@tatar.ru
ИНН 1629001040, КПП 162901001, ОГРН 1021605558435, ОКТМО 92642450


***Югары Табын авылы*** ***2018 нче елның «26» нчы декабре***

***КАРАР № 02-3***

**"Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегендә 2019 елда үзара салым акчасы хисабына башкарылучы төзекләндерү буенча чаралар исемлеге һәм бер тапкыр түләү (үзара салым) җыюны оештыру турында»**

2004 ел, 24 март, № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2017 елның 20 ноябрендәге 196 номерлы карары белән, 2018 елның 18 ноябрендә узган «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге территориясендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында" карарына нигезләнеп, 2019 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегендә бер тапкыр түләү (үзара салым) акчаларын үз вакытында җыю максатыннан **К А Р А Р  Б И Р Ә М:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегендә 2019 елга бер тапкыр түләү (үзара салым) күләмен 18 яшькә җиткән, нигездә шушы авыл җирлеге территориясендә яшәүче, «Түбән Табын авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге референдумында тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә расларга".

2. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, I, II төркем инвалидлар, ӘДР хәрби хәрәкәтләрендә катнашучылар, нурланыш алган яисә нурланыш авыруы, башка авырулар кичергән граждannar, Чернобыль һәлакәте аркасында инвалидлык алган кешеләр өчен үзара салым күләмен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә.

3. Бер тапкыр түләү срогын 2019 елның 10 нчы апреленә кадәр дип расларга.

4. Авыл җирлеге Башкарма комитетына үзара салым акчаларын җыюны каттгый әлеге Карар нигезендә оештырырга һәм авыл җирлеге Советы алдында хисап тотарга.

5. Үзара салым акчасы хисабына башкарылачак төзекләндерү буенча чаралар исемлеген расларга (1нче Кушымта).

6. Авыл җирлеге Башкарма комитетына үзара салым акчаларын каттгый әлеге исемлек буенча чыгымнар өчен кулланырга һәм авыл җирлеге Советы алдында хисап тотарга.

7. Әлеге Карарны Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://muslumovo.tatarstan.ru/.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

***Түбән Табын авыл җирлеге башлыгы*** ***/ Р. Ш. Кыяметдинов /***

*Мөслим муниципаль районы*
*Түбән Табын авыл җирлеге*
*Башлыгының*
*21.12.2018 нче ел, № 02-3 карарына*
*1нче кушымта*

**Түбән Табын авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы хисабына башкарылучы төзекләндерү буенча чаралар исемлеге**

1.Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
2.Халыкның ялын оештыру һәм хезмәт күрсәтү мәдәният оешмалары белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
3.Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;
4.Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру;
5.Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә төзекләндерүне оештыру;
6.Урам-юл челтәре элементларына, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исем бирү;
7.Җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм каты коммуналь калдыкларны транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;
8.Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
9.Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлү;
10.Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
11.Җирлек халкы күпләп ял итә алсын өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми кулланылыштагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иркенле үтеп керүен тәэмин итү дә.
12.Җирлекләрнең территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау;
13.Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарны тоту һәм карап тоту буенча чараларны гамәлгә ашыру.